Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Чукмарлинского сельского
поселения Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге
башкарма комитеты

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
14 августа 2025 года

**КАРАР**
№15

Чукмарлы авыл җирлеге Башкарма комитетының 05.04.2023 ел, № 4 «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашкан урыны турында мәгълүмат бирү турында»карарына үзгәрешләр кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең "Дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) турында Нигезләмәне раслау хакында" 14.03.2024 N 300 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «терекөмешле лампалар туплану урыннарын билгеләүче муниципаль актлар турында» 02.07.2025 № 09/13-09/3037 хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге башкарма комитеты, карар бирә:

1. Чукмарлы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашкан урыны турында мәгълүмат бирү турында» 05.04.2023 ел, № 4 карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

Карарның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

"Эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплану урыннарының урнашуы турында мәгълүмат әйләнә-тирә мохит торышы федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, шулай ук Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында (стойкаларында) урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.».

2. Чукмарлы авыл җирлеге Башкарма комитетының 07.08.2025 ел, № 13 «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашкан урыны турында мәгълүмат бирү турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Чукмарлы авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе — И.Х.Хадиуллин